

Фәния Харисова
Рәмилә Хисматуллина

# Күңел кыңгыраулары



Автор выражает благодарность
за содействие в издании книги
ОАО ХАНТЫ-МАНСИЙСКИЙ БАНК
и лично президенту банка Д.А. Мизгулину

Краеведческому сектору Нефтекамского р-на от авторов с любовью и уважением.

13.03.2013г

**Фәния Харисова**

**Рәмилә Хисматуллина**

# Күңел кыңгыраулары

Автор сүзе



Бу шигырьләр җыентыгына минем иң яратып иҗат иткән шигырьләрем кергән. Алар туган якка онтылмаслык җылы мәхәббәт хисләре белән язылган. туган ягымның кешеләрен сагыну аларны күрәсем килү мизгелләре белән сугарылган, кадерле китаб укучы дусларым аларны яратып җылы кабул итәрсез дип уйлыйм

Ихтирам белән фәния фәйзи кызы харисова .

# Яратамын сине Пойково

Ак чәчкәләргә күмелә,
Елның елында.
Пойково Себер шәһәре,
Минем җырымда
Пойково яратам сине,
Иң  матур шәһәр.
Җәйләрең зәңгәр чәчкәле,
Кышларың зәһәр.
Чагыштырып кара әле.
Кичә,бүгенен.
Исең китәр, үзгәргәнсең,
Нефтле җирем .
Пойковоны мактыйсың дип,
Әйтер кайбере,
Пойковосыз яшәп кара,
Кайтырсың кире .
Салават күпере төсе,
Җәен, кышында .
Бар гүзәллегең чагыла,
Минем җырымда

# Минем салымым

Салым юлларында җырлар туа,
Күңелләрем оча күкләргә.
Урманчылар,нефтчеләр ягы
Яхшы кешеләр яши Салымда.
Туган якка кайтыр юлларымда,
Салым мине җылы  каршылый.
Дуслар яши минем,бу якларда.
Чын дуслыкның белеп кадерен.

Салым сиңә сокланамын карап,
Киң урамнар, төзек йортларың,
Тасма кебек тезелеп киткән юллар.
Күз очыда җитмәс кырларың .
Дуслар, дуслар яши монда,
Себер җирен көндә баетып,
Эшчән, дәртле, җыр-биюле халкың,
Мәңгелеккә язып исемең.

## Бәхет икән

Бәхет икән синең белән,
Бер юлдан атлаулары.
Бәхет икән синең белән,
Бер уйны уйлаулары.
Нишләп әле соңлап кына,
Аңлыйбыз икән шуны,
Бәхетле көннәребезне,
Кайтаралмабыз инде.
Йөрәгемнең ,күңелемнең,
Иң елаган чаклары,
Сине, мине көтми хәзер,
Җиде юлның чатлары .
Синнән башка, миннән башка,
Яшәү юк ,дөрес икән.
Мәхәббәт утында янып,
Югалулар бар икән

## Кара икмәк

Кара икмәк ашап үстем
Кара икмәк көче тәнемдә
Кояш нуры. Яңгыр сафлыклары
Синең аша сеңгән күңелгә

Тормыш авырлыгы мәлләрендә
Бирешмәдем ачы чирләргәдә
Кара икмәк тәме иренемдә
Мәңгелек җыр ул күңелемдә
Күтәрәмен сине күкләргәдә
Күкрәгемдә кисәм телемең
Хакым юк бөртегендә төшерергә
Кара икмәк безне күтәрдең

## Өч кыр казы

Өч кыр казы очты баш өстемнән
Каңгылдашулары сагышлы
Казкайларым ямле язлар җитте
Очрашулар телим шатлыклы
Исән саулык теләп озатып калдым
Очар юлларына иминлек
Яз җилләре юлдаш булсын сезгә
Кыр казлары сезгә изгелек
Кай якларга очып баруыгыз
Әллә безне яраттыгызмы
Ерак араларны очып үтеп
Зәңгәр күлләренә яттыгыз
Яшел үлән үскән болыннарда
Хәл алдыгыз һәмдә матурлык
Челтер чишмәләрнең җырын тыңлап
Йолдызларга төнен очтыгыз

## Йөрәк

Нинди йөрәк күкрәк читлегендә,
Нинди йөрәк ,бердә аңламыйм ?
Зәңгәр тамырлардан ал кан ага,

Шундый йөрәк була микәнни?
Бер уч,бары учка гына сыя,
Сыйдырган ул бөтен дөняны .
Гафу итә,сөя, көтә белә,
Шундый йөрәк булса – буламы?

## Әнкәем

Төшләремдә күрәм әнкәемне,
Ак күлмәктән кара чәчләре,
Вакыт аша миңә килгән мәле,
Болын чәчкәләре исләре.

Хәлең ничек балам диясеңдә,
Ә үзең соң нинди чибәрсең.
Сары нурдан йөргән юлларың,
Җырлар бүләк миңә җибәрдең .

Барыйм мәллә димен яныңа,
Әй рәхәт әнкәй яныңда ,
Туктатасың мине елаудан ,
Сабырлыклар теләп ходайдан

Ә беркөнен килеп сарылдың ,
Тәрәз төбемдәге миләшкә.
Бик яратам кояш баешын.
Шушы миләш синә сердәшкә .

Төшләремә әни кер әле,
Чәчләремнән сыйпап үп әле,
Йолдызлардан тыңла җырыимны,
Төшләремә керми китмәле .

## Алма мәхәббәте

Иркә миләш төбенә тәгәрәде
Пар алманың берсе көз җи ткәч
Ялкынында эреде мәхәббәтнең
Чакруларны булды ишетмәс
Көз көннәре бигрәк матурланды
Челтәр пәрәвәзләр үрелде
Алма белән миләш мәхәббәте
Тиңнәре юк төсле тоелды
Тик ят ярны сөеп итң булмады алма
Ят агачта юк шул мәхәббәт
Кызыл миләшләрен.ле сөйләүләрен
Үз итмәде бүтән алмагач
Гомер шулай әрнеп үтеп китәр микән
Тап килмәсен шушы юоаулар
Дөняга бер килгәч кунак кына булгач
Ялгышулар үтсен гел читләп

## Яшә әле әни дөняда

Җан җылысы биреп бу дөняда
Яшәз әле әни яныбызда,
Өебез якты, җылылыгың синең,
Тәмле ашлар безнең алдыбызда.
Күңел өшегәндә, җаным туңган чакта,
Әнекәем керәм канат асларыңа,
Күңелең киң. Йөрәгең зур синең,
Әнекәем яшә әле дөняларда .
Рәхмәтләрең чәчкә булып ява,
Теләкләрең изге безнең тарафларга.
Безнең өчен бәхет, шатлык булып,
Исәнлектә яшә әни бу дөнҗада .

Әнидәндә зур кеше юк,
Изге корән юкны әйтмәгән.
Әни эзләрендә, сүзләрендә,
Оҗмаһ күперләре чигелгән .

## Йолдызым

Мең йолдызлар арасыннан,
Килеп чыктың атылып.
Күз камашты синең нурдан.
Калдым каушап, онтылып.

Әй йолдызым еракта ы,
Кайчан килеп җиттең соң ?
Күпме көттем,күпме көттем,
Йолдызым син йолдызым!

Бу дөняда белми үтсәм,
Син йолдызның җылысын.
Яшәмәгән булыр идем,
Рәхмәт сиңә язмышым.

Зәңгәр күктә йолдызлар күп,
Булсын берсе синеке.
Бәхет бит ул, үз йолдызың,
Итсә сине үзенеке

## Дуслар белән

Шатлык белән тусын хәр туган көн,
Изге хәбәр генә ишетик.
Бер-беребезгә көлеп дәшеп кенә,
Дусларча без гомер кичерик.

Бу дөняның авырлыгын дуслар,
Беләбез бит инде болайда.
Киртә-корта кормый, тормыш юлларында,

Җырдай итик тормыш болынын.
Бер елмаеп дәшсә очраган дус,
Бөтен дәня китә яхшырып,
Бер-беребезгә изге теләкләрдә генә,
Йөрик дуслар, берүк яктырыйк .

Дуслык кадерен белеп, олы итеп,
Бәхет-шатлыкларны бүлешеп.
Бергә гомер кичерү, олы бәхет,
Әй күңелле шуны белегез.

## Б әхет кошы сездә

З әөһрә йолдыз булып.күңел түрем тулып
Җ ылы назым булып килдегез
С езсез ничек яшәгәнмен икән
Ә ллә еллар аша белдегез
Шушы җирдә бергә яшәгәнбез
Җ илләр искән кышлар үтелгән
Яшел җәем булып сез килдегез
Г омер юлым яртысы сүтелгәч
Ә шулайда шатмын бәхетлемен
Сезнең дөня зәңгәр бөеклек
Сезне күрдем ак көнләшү миндә
Сездә белдем бик күп серлелек
Ак канатлар ике аккошыгыз
Х одай сезгә бүләк китергән
Кү рми киткән булсам ике кызыгызны
Гомер юлым мине кичермәс
Сезнең дөня затлы кәравансарай
Яшәп туймас көннәр чираты
Куркам сезгә карап аһ итәргә
Күз тимәсен сезгә берчакны
Рәхмәтлемен бар булмышым белән
Сезне якын итеп белгәнгә

Бәхет кошы сездә яши дуслар
Сез бәхетле кошлы булганга

Әнвәр шәриповка
Фәйрүзә шәриповага
Таңчулпан тансылу
Кызларына

## Алтын көзем

Көзгә кереп бара идем,
Яфрак ява эзләргә.
Карашыңнан чәчкә аттым,
Карамыйча көзләргә.
Көзләргенә тиямени,
Кузгалган күңелемә.
Ак бураннар дуласада,
Әй рәхәт бүген миңә.
Сөю үзе зур бәхет бит,
Бәхетнеңдә ниндие,
Яшел күзләрдән күрдем мин.
Сине чиксез сөюне.

## Күңелем

Тәбигаткә әллә ниләр булды
Яңгыр чиләкләре тишелде
Көнен—төнен җилләр дуладылар,
Тау—тау булып болыт ишелде
Көз килүе .алтын көзнең шулай.
Кышка җайлап кына барышы
Үзен күрсәтмичә китәмени.
Көз килүе шушы түгелме.
Йомшак карлар явыр.

Азак тагы эрер.
Үзәкләргә үтәр җилләре.
Ә беркөнен ак кар ятса җиргә.
Канатланыр күңелем түрләре.
Менә шулай җайлап кына.
Күңелем тынычланыр. Җайланыр.
Ап-ак кышның зәһәрлеген күреп.
Шигырьләргә күңелем төренер

## Көз ае

Алтын- җитен көзем ашыкмыйсың.
Киләсе кыш әллә кауламый.
Көнгә чыксаң урам өсләрендә.
Сибә сары нурын кояшың.
Басу өсләренә җәеп куйгансың син.
Кара җирең тасма сарылган.
Ара-тирә яшеллегең калып.
Көзлек билгеләре сарылган.
Ашыкмыйсың әле. безне кинәндереп.
Кунак итим дисең сыйлардан
Сөеп туялмаслык.күреп туялмаслык.
Йөртим дисең тыныч төннәрдә
Китәрсең син, барыбер китәрсең бит,
Аямыйча кышлар килерләр
Моңсуланып калган шагыйр генә,
Беркөн сине өзелеп сагыныр
Җәй мәхәббәтем туган ягыма
Җиләк пешкән, иртән чык тамчысы,
Йомшак кына аңа сарылган.
Яшел болын чәчкәләрен гизеп,
Чәчкә диңгезеннән йөгерәм.
яшел җәем, сары кояшкаем,

алмаларың әле пешәсе,
чияләрең, кызыл чияләрең .
алларыма өзелеп төшәсе.
Ак тупыллар ак чәчләрен әле,
Йомшак җилдә җиргә коймаган ,
Чәчкәләрдә сөеп, безне кешеләрне ,
Кат –кат ата, бездән туймаган
Болыннарда йөрдем сусап беттем,
Җиләкләрен ашап туймадым,
Туган җирем син бер әүсең, беләм!
Синнән башка җирне яратмам !

## Әтием

Чалгы тавышы чаң-чаң килә,
Печән чапкан болыннарда.
Тургай сайрый бик-биектә,
Зәңгәр күкнең кочагында.
Бала чакның гамсезлеге,
Бигрәк тиздә уза икән,
Әти җыры колагымда,
Җырлап йөрим юлларымда.
Сагынырбыз әти сине,
Юксынырбыз булмавыңны,
Истән чыкмас узган гомерең,
Белалмәдек уйларыңны.
Күңел елый, зур югалту,
Гафу итмим бу ялгышны.
Шомырт кара күзләреңне,
Очратсамчы бер язмышта

## Туган ягым туган авылым

Җаным тәнем белән сеңдем сиңә.
Туган ягым сине сагынам
Кара туфрагыңны иснәп туялмамын
Юлым тәшеп сиңә кайталсам
Егылып ятып яшел чирәмендә
Тыңлар идем җилләр җырлавын
З әңгәр күкләрендә кыр казларың
Саубуллашып канат болгавын
Күпме җырлар җырлап туялмамда
Сине мактап сине данлапта
Моңаеп кына авылым утырасың
Кайчан гына сиңә кайтсамда
Шат ланасың синдә эти әни кебек
Кояшың мул суың шифалы
Җанкаема рәхәт шатлык иңә
Үлән чәйләрендә сихәтле .

## Ике апам

Көне төне әни күңеле кебек
Күзәтәсез ярдәм итәсез
Изге җаннар апаларым минем
Яшәвемдә көч хәл бирәсез
Ходай биргән сезне бу яшәүдә
Шатлык итеп сезне апамнар
Тәбигатнең сабыр чәчкәләре
Бүләк сезгә җәйге яланнар
Күңел күген болыт каплаганда
Кояш күктән көлми караса
Сез апамнар сихәт фәрештәмнәр
Язган җырлар күңел кочалар

Ике апам ике күз алмам
Йөрәгемнең нечкә кыллары
Яннарымда сез булганда һәрчак
Җырлы булыр гөмер юллары

## Әти бакчасы

Бакча утырткансың уллар үстергәнсең
Йорт салгансың гомер иткәнсең
Бу дөнянын бар йоласын үтәп
Эшең беткәч кенә киткәнсең
Әтекәем дөняларда синдә
Әни кебек бигрәк якынсың
Зур эшләрең онытылмас мәңге
Онытырлык әти түгелсең
Бакчаларга керсәм тын каламын
Дөня мәшәкатем басыла
Җанкаема җылы урын монда
Сагыш сагнуларым юыла
Яшел алма алмагачтан өздем
Сарысында татып карадым
Кояш җиләкләре баланнарны
Биткәемә тидереп яраттым
Зәңгәр төннәр җырын җырлый җырлый
Кояш нурларына күмелеп
Яши бакчаң әти тормыш дәвам итә
Еллар мизгеленә бәйләнеп

## Үзем генә беләм

Җир җиләге пешкән аунап җыйдым,
Мин яраткан арткы болында.
Сине сөюләрем ,өметләрем,
Әйләнделәр эреп болытка.
Бәхетледә булдым, әйтмәс идем,
Чатнап көлдем ялгыш адымнан.
Түзү\ләрен үзем генә беләм,
Узмышлар юк икән ,язмыштан.
Беркем этәрмәде,аны сөй дип.
Алмаларның өздем алсуын.
Тышы матурларын сайлап алдым,
Ачы булды тәмен татуы .
Бар ягыда тулы булган кеше,
Бик сирәктер шушы дөнҗада
Күзләремдә көлү, төпләрендә сагыш,
Сагышларны җиңеп син кара .

## Язны көткәндә

Ап –ак карлар явып кыш булдыла ,
Язны күңел ашкынып көткәндә .
Ния кирәк инде соңгы карлар ,
Әкрен генә кышлар киткәндә
Тә бигатнең кызык бер көне бу,
Әллә елый, әллә туктала ,
Вакыт- вакыт карлар явып ала ,
Ә бер вакыт яңгыр кояла
Ә бер көнен буран, ачы буран,
Капкаларны сыра аямый
Кешеләрне юеш ап-ак карлар ,
Очырталар берни карамый .

Күңелем барыбер сагнып язны көтә,
Яз көннәре килми китмәсләр,
Көтә белик, түземлелек белән,
Килер язлар, килми китмәсләр.
Кояш чыгар болыт арасыннан,
Бу кылыкка улда түзәлмәс.
Яз язлыгын итәр, гомер үтәр,
Гомер сәгатләре тукталмас.

## Җан

Берөн үлгәч чыккан җаным белән,
Сөйләшердә идем онтылып,
Сорар идем күп нәрсәләр белми,
Ния болай гомер үтте дип .
Ничә тапкыр яшәгәнне белгәч,
Үпкәләрдә идем җаныма.
Ния инде яшәгәндә җирдә,
Сер ачмадың гомер җаенда.,
Күп нәрсәне аңламыймдыр бәлки.
Аллаһыга гына буйсынам.
Шуңа аңым минем аңламыйдыр,
Сине җаным- җаным туйсынып
Җаным минем яратамын сине ,
Килче әле кысып кочаклыйм,
Күзләремә күрен, нәни кызчык булып,
Шулай итеп икәү тын калыйк .
Аерылып киткәч миннән карап торып,
Ни әйтерсең икән тагыда.
Ә мин сине сагынырмын тагы,
Чакырырмын кабат яныма .

## Сабан туе

Язучыдан нәрсә бүләк,
Бер матур шигыр диләр.
Ә җырчыдан бер матур җыр,
Сабантуйга зур бүләк.
Биюченең бер бию,
Йөрәкне җилкендерә,
Сабан туе җыйды безне.
Үзенең киң түренә.
Чәчкә аткан болыннарда,
Бүгенге көнне безгә,
Яңгырыда шаулап ява ,
Себеребез җирендә .
Котлы булсын сабан туе,
Хезмәт туе бүгенен,
Сәләмәтлек, бәхет, шатлык,
Сезгә бүген телимен .

## Күңелле такмаклар

Басмалары,басмалары,
Басасы килеп тора,
Синре генә,сине генә,
Күрәсе килеп тора.

Кичкә калып, кичкә калып,
Тәрәзәләр сөртмәгез ,
Беренченнән ялгыз калып,
Икенчесен көтмәгез.

Бу гомернең үткәненә,
Күңелем сызлап куя.
Үтмәсәдә нишләр идең,
Үтсәдә әйдә тыйма.

Бардым сезгә,күрдем сезне,
Бик бәхетле икәнсез.
Һич көнләшмим,тик шатланам.
Һәрчак шулай яшәгез.
Туганнарым һәм дусларым,
Булсалар киң күңелле,
Рәхмәтлемен чын күңелдән,
Яшәүләрем бәхетле .
Йөрәгемне җәлләмәмен,
Кадерле дусларыма.
Туганнарым , якыннарым ,
Булыгыз яннарымда

## Гади кеше.

Гади кеше булып,яшәп карыйм әле.
Юләрләрдәй көлеп – шаярып.
Әйткәннәргә исем китми генә,
Исем китми генә йөгереп.
Сөйләсеннәр әйдә сөйләсеннәр,
Хәлләремнең кыен икәнен ,
Тик белмиләр алар , тик үзләре,
Ничек яшәр иде кичләрен
Сөйләсеннәр әйдә, сүз кирәк бит,
Ишетмичә йөрим елмаеп.
Минем елмаюым-кем өчендер үлем,
Үлемнәрне кара күтәреп .
Сөйләсеннәр әйдә,сөйләсеннәр,
Минсез яши алмый икәннәр.
Еласада күңелем, күзем көләр,
Үткәннәрне үзем уткәреп .

## Яшә әле әни дөньяда

Җан җылысы биреп бу дөньяда
Яшәз әле әни яныбызда,
Өебез якты , җылылыгың синең,
Тәмле ашлар безнең алдыбызда.
Күңел өшегәндә,җаным туңган чакта,
Әнекәем керәм канат асларыңа,
Күңелең киң. Йөрәгең зур синең,
Әнекәем яшә әле дөньяларда .
Рәхмәтләрең чәчкә булып ява,
Теләкләрең изге безнең тарафларга.
Безнең өчен бәхет, шатлык булып,
Исәнлектә яшә әни бу дөнҗада .
Әнидәндә зур кеше юк,
Изге корән юкны әйтмәгән.
Әни эзләрендә, сүзләрендә,
Оҗмаһ күперләре чигелгән .

## Яратам сине миләш

К өздә җитте тагы, миләш матурланды
Янып пеште тулган тәлгәшләр,
У йнак җилгә иркә тирбәләләр,
Минем әчен алар пешкәннәр.
Миләшләрем сезгә гашыйкмын мин,
Ел мизгеле нинди булсада.
Сезгә карап миндә матурланам,
Гомер язым яңы үтсәдә.
Миләшләрем, кызыл миләшләрем,
Кояш сезне сөеп кызарткан.
Сезнең сабырлыктан, матурлыктан.
Миңә тыныч, сезне яратам

Көзнең әле соңгы көне түгел ,
Яфракларың әле яшелле,
Кызыл тәлгәшләрең, баллы тәлгәшләрең ,
Яшлегемнең яме шикелле .

Хисматуллина /аюпова/ рэмилэ хаернас кызы



Башкортостанның Благовещен районы Иске Илек авылында туып үсте

Минем җан дустым ,балачак дустым. Шаулап торган йомшак сулы, кечерткэн куаклары баскан яшел үлэнле Илек елгасында су коенып, минем шигырьлэремдэ мактап туймаган Алачык елгасының шифалы суын эчеп, энҗе бөртеклэре кебек ялтрап торган дулкыннарында колач җэеп йөздек .Бэхетле балачак үтеп китсэдэ без араларны беркайчанда өзмэдек,тормыш юлларыбыз аерылгачта югалтышмадык Язмыш кушуы буенча ул Эбҗэлил районы егетенэ кияүгэ чыгып бэхетле тормышта яшэп ул һэм кыз үстереп ,аларга югары белем биреп зур тормыш юлына бастырганнар .шигьри күңелле дустымның язмаларын укыгачта мин таң калдым,алар барсыда бу дөньяны тирэнтен аңлаган,кешелэр тэбигатен үтэдэ күрүе ,гади кешенең игьтибарда итмэгэн нэрсэлэргэ аның икенче карашлы булуы мине аның шигырлэренэ гашик иттедэ куйды Туган якны ярату.аның кешелэрен,балачак хэтирэлэре онтылмаслык булып дустым күңелендэ калган .Кадерле дустым яз калэмең үткен булсын, бу синең тэүге адымнарың дип уйлыйсы килэ тагында матур-матур шигырлэреңне китаб битлэрендэ күрергэ язсын .

Иң изге телэклэр белэн җан дустың Фэния Харисова

## Илегем

Илектә дә таңнар шулай,
алсуланып ата микән?
Кайнар кояш кич житкереп,
Моңсуланып бата микән?
Алачыкның суы хаман,
йомшак микән, тәмле микән?
Кисендеге кәчуәне
куе микән, ямле микән?
Сыңар колаклы урамым
яшел хәтфә чирәм микән?
еллар аша мин үземне
Илегемдә күрәм икән.

## Йолдыз парлар

Куктә парлар парлаганда,
Кемнәр кемгә тәгаен?
Бер шаяны кушкан безне,
эксперимент, могайын.
Син ут булсаң , мин су булдым,
Бастым кызуларыңны,
Аңлашмый да киттек кайчак
булешеп донъяларны,
Авыр холкым сәбәпчеме,
Өскәә үрлей алмадың,
Кара эштә утә гомерең,
түрәлеккә бармадың.
«әтәч» белән «күсе» пары,
идеаллы пар тугел,
Дип яза йолдызнәмәләр,
тик гомерем зар тугел.

## Жир жиләге

Җәйдә генә жир жиләге пешә,
каен жиләк, тагы бөрлөгән,
Кышның салкын буранына тузгән,
чыдамнарга бүләк – бер дигән!
Тәбигатнең изге могжизасы:
Жирнең кукрәгеннән көч алып,
Кыска җәйдә ничәмә төр җимеш,
Өлгөрә алланып, балланып.
Күз явын алырлык матурлыгын,
тел йтарлык тәмен, хуш исен,
Зәһәр салкыннарда хәтерләрбез ,
Сакларбыз кунелдә җәй төсен.

## Кунак апа

Миңә 5 яшь, бездә кунак,
әби кайткан еракпан.
Илек кызы икән ул да,
Илен сагынып кайткан.
Барысы әйбәт , тик мин генә,
Бәйле булдым әбигә,
Минсез бер кая да бармый,
Танымый бер кемне дә.
Нишлисең бит, таныштырам,
Авылдашлары белән,
Исемнәрен сайрап бирәм,
Кушаматлары белән.
Беркөн Илек буасында,
Керләр юды басмада,
Аякларын суга тыгып,
Утырып ала тактада.

Миңә эссе, салдым хәбәр
Тешсезләр тормый түзеп:
«Бигрәк озак мыштырдадың,
Буада   тоташ кубек,
Кайтыйк инде, житәр сиңә,
Сабынны кү п бетердең»,
Әле дә сөйләп көләбез,
Телең  ачы, үтердең!

Хатын-кызның куңел кылкайлары
Иллеләргә житсә – нечкәрә.
Эле генә жырлый ул моңланып,
әле генә жылап жибәрә.
Куз яшләре аша елмая да,
Уйга кала, барлап гомерен.
Тормыш сынауларын куя гына,
Бер кем белми ниләр күререн.
Балалары   исән-сау булсыннар,
Бер Ходайым! бир бәхетләрен,
Саулыкларын, эшен-шөгылен дә,
Гомерлек саф мәхәббәтләрен.
Күңел   тынычлыгы табып алып
Әйләнә  ул көчле, сабырга,
Хатын-кыз тирәли әйләнә  Жир
Тотырлык көч   кирәк табырга!

## Юкә

Барлык  агач куаклардан  соңлап
Чәчкә ата юкә июльдә
Сүз кодрәте җитмидердә  әле
Хуш исләрен сөйләп бирергә
Шомырт сирин исе язда кала

Сагнып кына кала сөйләргә
Яшел күлмәк кигән чибәркәйдәй
Юкә балкый аңкый җәйләрдә
Сандугачлар арып тынган мәлдә
Юкә чәчкәсеннән бал тама
Яшкелт нәфис сары чәчкәләрне
Өзсәң әгәр берүк бел чама
Сулыш саен тула күкрәгеңә
Туган якның юкә –хушбуе
Уфа юкәләрен тыңлый-тыңлый
Баллап чәйләр эчик кыш буе

## Яшен

Кульяулыктай булып ялралдыда
Күк йөзенә болыт таралды
Гөрселдәде күкрәү тавышы
Ялтырады яшен-ут ташы
Болытлардан яңгыр коелды
Барлык дөня суга коенды
Утлы камчы янә ялтырый
Аяу көтеп урман калтырый
Бәлә-казаларсыз яу яңгыр
Яшен утларында көйдермә
Бәрәкатең белән яу яңгыр
Боз- борчакларыңны тидермә
Үтте яңгыр яшен тыелды
Бар тереклек иһлас сөенде
Нәни инеш булды зур дәрья
Кыеп карагысыз саф дөнья

# Ижад

Белгмәгәнмен: кунелем чишмәсендә
Мөлдөрәмә булган моң, сагыш
Кайдан сизден аны, син дускайым
Мин бит көтмим һич тә зур табыш.
Каләм тибрәт дисең, сузләр сайлап
Канатлы суз мине тыңлармы?
Сиңа буйсынгандай буйсынырмы
Сиңа жырлагандай жырлармы?
Энже бөртөкләре булып сузләр
Шигри калыпларга сыйганчы
Жанны тамырыннан суырып алып
Сафлап, пакълап кире куйганчы.
Нинди зур көч кирәк , сәләт кирәк
Илһам чишмәләре атырлык!
Дустым, җаным! яз син яңы жырлар
Ижад иту- үзе батырлык.

# Әти

(Минем тарихымны беләсез бит)
Мин тугачтан әтием куангансың
Кулларыңа алып йөрөткәнсең
Бишегемә салып тирбәткәнсең
Уйнап «үчти-учти» иткәнсең.
Исемне дә үзең кушкансың син
Малайдан да артык күргәнсең
Ун малайга да мин алмаштырмыйм
Кызымны дип күкрәк төйгәнсең.
Таркалган гаилә - бардыр сәбәп
Сәбәпсез өзелми яфрак та
Язмыш безне гомергә аерган

Ташламаса да бик еракка.
яшәдек тә инде бер авылда
Тик нишләптер мине күрмәдең
Ни хәл кызым диеп эндәшмәдең
Ирис кәнфит алып бирмәдең.
Бала күнеле юктан майдай эри
Кәмсенүгә исә ул ката
әти яратуын тоймадым мин
Мәңге төзәлмәслек бу хата.

## Күбәләк

Күбәләккәй гөлгә кунган
Төсен охшатты микән
Канатларын җилпи-җилпи
Хисен бушатты микән
Тагын очты гөле калды
Зур ачып таҗ керфеген
Чык тамчысы җемелдиме
Әллә яшь бөртегеме.
Көтә гөлләр өметләнеп
Күбәләк түгәрәген
Назлы җанга кайчак насып
Җиңеле- җилбәзәге
Күбәләкләр чәчәк сайлый
Тәменме---төсләренме
Әллә нурлы карашынмы
Әллә хуш исләренме

Отпечатано:
«Бугурусланская типография» – Бугурусланский филиал
ГУП "РИА "Оренбуржье"

Объем 1,75 п.л. Гарнитура Times
Заказ № 2555 Т. 120



